НӘТИҖӘЛЕ ЭШ
Рөстәм Миңнеханов төбәк башлыкларының эшчәнлек рейтингында икенче урынга чыккан

> 2

ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫНДА
Татарстанда пошилар һәм кыр кәҗәләре арткан

> 2

ГАЛӘМГӘ ЮЛ
Арчада балаларны космос белән кызыктырмакчылар

> 3

ХА-ХА-ХАНӘ
Кызык-мызык, булмас димә, фототөрткеләр монда

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 128 (28901) | Шимбә | 3 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

АКЧА ДӘВАЛАМЫЙ

СОЦИАЛЬ ПАКЕТ АЛУ ӨЧЕН ГАРИЗАНЫ 1 ОКТЯБРЬГӘ КАДӘР ТАПШЫРЫРГА КИРӘК

Дарумы, акчамы? Социаль пакетка хокукы булган кешеләрнең сайлау өчен бер айга якын вакыты бар. Әгәр алар дару алырга тели икән, 1 октябрьгә кадәр гариза язарга тиеш. Шул вакытка өлгермәүчеләргә тагын бер ел көтәргә туры киләчәк. Гаризаны узган елларда язган кешеләргә аны яңарту кирәкми. Дару урынына акча сайлап, аннары авыр хәлдә калучылар да бар икән. Шуңа да белгечләр алдан хәстәрен күрергә өнди.

Соңыннан үкенерлек булмасын. «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Фәридә Яркәева бу хакта кат-кат искәртте. Татарстанда 317 мең кеше социаль ташламадан куллана. Шуларның 120 меңе акча урынына дару сайлаган.

– Бездә дарудан баш тартучылар 63 процентны тәшкил итә. Федераль күрсәткеч югарырак – ул 85 процентны тәшкил итә. Соңгы ун ел эчендә Татарстанда дару сайлаучылар 9,5 процентка артты, – диде министр урынбасары, бу эштә матбугат чараларының роле зур икәнен искәртеп. – Без бу хакта 2005 елдан бирле сөйлибез инде. Авырулар өчен борчылганга бу. Әйтик, көтмәгәндә генә яман шеш, шикәр диабеты, психик авырулар килеп чыкты ди. Бу очракта дару урынына алган акча гына җитмәячәк. Әлеге авыруларны дәвалау шактый кыйммәткә чыга. Яшерен-батырын түгел, соңгы елларда шикәр чире «чәчәк ата». Илдә һәр ун ел саен 10 миллион кешегә бу диагноз куела. Соңгы 40 елда шикәр чире белән авыручылар саны 500 миллионга җитте. Татарстанда да авыручылар күбәя. Соңгы вакытта кечкенә балаларда да шушы авыру табыла. Ә бит аны дәвалау бик кыйммәткә чыга. Шунлыктан социаль пакетсыз кала күрмәгез.

Социаль пакетка хакы булган кешеләрнең күбесе өчен балалары хәл итә икән. Шул сәбәпле урында гына ятып торучылар дарусыз кала. Министр урынбасары андыйларга да иң элек авыру хакында уйларга киңәш итә. Ә кайбер очракта киресенчә, әти-әни безгә әйтмичә социаль пакеттан баш тарткан, дип килүчеләр дә бар, ди. Казанның Дәрвишләр бистәсендә яшәүче 82 яшьлек Сания Яруллина узган ел, акчага кызыгып, дарусыз калган.

– Әни каяндыр ишетеп кайткан да, дару алганчы, акча алам дип, гариза язган. Ә бит ул ике елдан артык яман чир белән көрәшә. Аңа кирәкле даруларны сатып алыр өчен күпме акча кирәк! Дарулар бирелми башлагач, утырып еладым хәтта. Әни аякта йөрсә дә, тиешле даруыннан башка тора алмый. Алар кыйммәт икән. Энем белән бергә бер ел буе үзебез сатып алдык. Быел инде җәй башында ук гариза язып куйдык. 1 мең сумга кызыгып, 10 мең сум түләп булмый бит инде, – ди кызы Ләйсән Кашапова.

Яман чир дигәннән, республикада аны иртәрәк ачыклый башлаганнар. Авыруларның гомере дә 5 елга озайган. Элек чир соңгы чиктә генә ачыкланса, хәзер 1, 2 нче стадиядә үк беләләр. Фәридә Яркәева сүзләренчә, моннан 10 ел элек республикада яшәүче һәр 62 нче кешедә яман чир барлыгы ачыкланса, соңгы елда һәр 35 нче кешегә бу диагноз куелган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Яман шеш диагнозы белән яшәүчеләр шактый. Бала алып кайтучылар да бар хәтта. Шуңа күрә һәрдаим үзеңне кайгыртып торырга, вакытында тиешле дарулар эчәргә кирәк. Әйләнәм дә шуңа кайтам – акча урынына дару сайлагыз, – диде ул.

Чаллыда яшәүче, шикәр чире белән интегүче Гөлфия Сабирҗанова да, бушлай бирелә торган дарулар арасында гомер буе эчкән даруым юк дип, алардан баш тарткан булган.

– Коронавирус башлангач, хәлем начарланып китте. Даруларның да безгә кирәклесе кайтмый башлады. Мин бер ел дару урынына акча алдым. Әмма быел яңадан гариза язарга булдым әле. Шикәр чирем катлауланды. Үзем эчә торган дару гына ярдәм итми башлады, – ди ул. – Күршемдә 80–85 яшьлек әбиләр яши. Алар тиенен тиенгә җыеп дару ала. Бушлай алып булганын белмиләр икән. Аларга да әйттем әле. Барабыз, диделәр.

Табиблар кешеләр авыру азып киткәнче сузып йөри дигән фикердә. «Көн саен диярлек йөрәк-кан тамыры авыруларыннан интегүчеләр мөрәҗәгать итә, – ди Казанның Тимерьюлчылар сырхауханәсе бүлек мөдире Ләйсән Шәйхуллина. – Кан басымыннан зарланмаган бер кеше дә юк. Шикәр авырулары белән интегүчеләр дә шактый. Без поликлиникага килгән авыруларга социаль пакет хакында аңлатабыз. Өлкәннәрне балалары да кайгыртсын иде. Аларның күбесенең хәтере дә начар, ничек гариза язасын да белмиләр. Без аларның хәлен җылы сүзебез белән генә җиңеләйтә алабыз, дару бирә алмыйбыз. Шуңа күрә дөрес сайласыннар иде».

Гөлгенә ШИҺАПОВА

СОЦИАЛЬ ПАКЕТ КЕМНӘРГӘ ТИЕШ ҺӘМ АНЫ НИЧЕК АЛЫРГА?

Быел дару өчен бирелә торган акчаның суммасы аена 1 мең сумны тәшкил итә. Социаль пакет сайлаган кеше дару гына алып калмый, аларга санаторийга юллама, дәвалану урынына бушлай бару һәм кайту, тимер юл транспортында бушлай йөрү мөмкинлеге дә бирелә. Шулай ук аңа бер диагнозы буенча гына түгел, башка төрле чирләренә дә дәва бирә торган кирәкле бөтен дарулар бирелә.

Аннан Бөек Ватан сугышы инвалидлары, анда катнашучылар, яуда үлгәннәрнең тол хатыннары, балалары, Ленинград блокадасында булучылар, төрле бәрелешләрдә булган ветераннар, радиациядән зыян күрүчеләр һәм барлык төр инвалидлар файдалана ала. Социаль пакетны алу өчен гаризаны Пенсия бүлекләренә тапшырырга кирәк. Дару киләсе елның 1 гыйнварыннан бирелә башлый.

Татарстанда – өй туйлары

Татарстанда Территорияләрне үстерү фондының күзәтчелек советы игътибарга алган барлык проблемалы торак йортлар кулланылышка тапшырылган. Бу хакта фондның күзәтчелек советы рәисе – Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин белдерде.

«Федераль һәм төбәк структураларының бердәм эшләве нәтиҗәсендә бу эш уңышлы тәмамланды. Элегрәк тугыз комплекста 1689 өлешче фатирлы булды. Тагын 175 кеше Комиссар Габишев урамындагы йортка ачкыч көтә. Төзүчеләргә башкарган эшләре өчен рәхмәт», – диде Марат Хөснуллин.

Хәзерге вакытта проблемалы объектларның бердәм реестрында Татарстан территориясендәге тагын алты йорт кала. «Аның икесен якын арада исемлектән алачаклар. Чөнки Комиссар Габишев урамындагы йорт файдалануга тапшырылды, ә Гадел Кутуй урамы, 83а адресындагы объект өчен 86 өлешчегә акчалары кире кайтарылды», – дип билгеләп үтте фонд идарәчесе Константин Тимофеев.

Шул рәвешле калган дүрт объект республиканың юл картасына кертелгән. 186 өлешченең хокуклары 2022 елның декабренә кадәр торгызылырга тиеш. Шул рәвешле агымдагы ел ахырына төбәктә алданган өлешчеләр проблемасы хәл ителергә мөмкин, дип нәтиҗә ясады Тимофеев.

Нефть чыгару арткан

Татарстанда җиде ай эчендә нефть чыгару 20,5 млн тоннага кадәр җиткән. Бу, узган елның шушы ук чоры күрсәткечләре белән чагыштырганда, 4 процентка күбрәк, дип хәбәр итә Татарстанстат.

Агымдагы елның җиде аенда 538,2 млн куб метр нефть газы чыгарылган. Бу да узган ел белән чагыштырганда 8,3 процентка күбрәк.

Яңа төр вакцина

Татарстанда коронавируска каршы прививканы борынга ясый башлыйлар. Киләсе атнадан «Спутник V» вакцинасын интраназаль рәвештә ясатырга мөмкин булачак. Бу хакта Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы хәбәр итә. Даруны борынга салу өчен шприцка кидертелә торган махсус атомайзерлар сатып алганнар.

Искәртеп үтик: бу вакцина да ике өлештән тора. Аны өч атна аралык белән ике тапкыр борынга салалар. Ул борын һәм йоткылык куышлыгында инфекцияләргә киртә булырлык иммунитет булдыра.

Табиблар интраназал вакцина ревакцинация өчен кулай дигән фикердә. Шулай ук аны ясау психологик яктан да җиңелрәк. Көзге чорда сәламәтлек турында аеруча кайгыртырга кирәк, дип искәртә белгечләр.

Күбрәк түләсеннәр

Татарстанлыларның 64 проценты мәктәп укытучылары аена 100 мең сумнан артык акча эшләргә тиеш дип саный. hh.ru хезмәте үткәргән сораштыру нәтиҗәләре шул хакта сөйли. Сораштыруда катнашучыларның тагын 20 проценты мондый белгечләр өчен лаеклы хезмәт хакы 61–100 мең сум аралыгында дигән фикердә. 5 проценты аны 30–60 мең сумлык дип бәяләгән.

Портал мәгълүматлары буенча, 2022 елда Татарстанда укытучы вакансиясенең уртача хезмәт хакы 32,5 мең сум тәшкил итә. Тәкъдимнәрнең 3,2 процентында гына керем 100 мең сумнан артып китә.

Яңалык

Сентябрь үзгәрешләре

2022 елның 1 сентябреннән яңа кагыйдәләр һәм законнар үз көченә керә. Алар безнең тормышка ничек тәэсир итәчәк? Иң мөһимнәрен укучыларыбыз игътибарына җиткерәбез.

➤Фатирларны кечкенә өлешләргә бүлеп сату рөхсәт ителми. Яңа закон нигезендә бер кешегә тиешле мәйдан 6 кв. метрдан да кимрәк булырга тиеш түгел. Дөрес, күчемсез милекнең мирас итеп бирелүе, ана капиталын куллану яки хосусыйлаштыру очраклары искәрмә булып тора.

➤1 сентябрьдән «Кулланучылар хокукларын яклау турында»гы Законга үзгәрешләр кертү нәтиҗәсендә, кибетчеләргә сатып алучылардан, әгәр алар үзләре теләмәсә, шәхси мәгълүматлар җыю тыела. Бу кагыйдә интернет-кибетләргә дә кагыла. Сатып алучы мондый мәгълүматның ни өчен кирәклеген язмача аңлатуларын таләп итә ала. Әгәр кибет мәгълүмат бирмәгән өчен сатып алучыдан баш тартырга теләсә, аңа штраф салынырга мөмкин. Шулай ук сатучыларның түләү ысулын (карта яки акча) үзләре теләгәнчә таләп итәргә дә, җитешсезлекләр булганда товарны алыштырмаска яки акчаны кайтарып бирмәскә дә хокуклары юк.

➤«Реклама турында»гы Законга да төзәтмәләр кертелә. Хәзер һәр цифрлы реклама махсус төзелгән реестрга кертеләчәк. Һәрберсенә «реклама» дигән билге куелачак. Бу баннерларга да, видеоларга да, текст блокларына да, социаль челтәрләргә дә кагыла. Яшерен реклама тыела.

➤Торак кодексында да үзгәрешләр бар. Хәзер күпфатирлы йортларда идарәче компанияне алыштыру өчен торак милекчеләре 50 процент тавыш җыярга тиеш. Элек моның өчен 25 процент та җитә иде. Экспертлар фикеренчә, бу яңалык идарәче компанияләрнең «урынны сатып алу» очракларын киметәчәк. Әмма бер проблема да килеп туа: үз эшенә салкын караган компанияне алыштыру катлаулырак булачак.

➤Дәүләт үз билгеләнешендә кулланылмаган гаражларны тартып алырга мөмкин.

➤Гражданнар кодексы да үзгәрешсез калмый. Элек, әгәр торакны үз билгеләнешендә кулланмыйча, күршеләрнең хокукларын бозсалар, милекчеләрне торактан мәҗбүри рәвештә чыгара алалар иде. Хәзер исә бу кагыйдә машина кую урыннарына, гаражларга, сарайларга да кагыла. Мәсәлән, гараж урынында автоюгыч эшләсәләр, дәүләт башта кисәтү ясарга, аннан хуҗадан ул гаражны мәҗбүри сатып алырга мөмкин.

➤Студентларга шатлык – стипендиянең күләме күтәрелә. Россиядә аның күләме ел саен карала, гадәттә инфляция дәрәҗәсен фаразлаганнан соң индексацияләнә. 2022 елның 1 сентябреннән аның күләме 4 процентка күтәрелә. База стипендиясе көллият һәм техникумнарда – 638 сум, югары уку йортларында – 1755 сум. Социаль стипендия көллият һәм техникумнарда – 958 сум, югары уку йортларында – 2634 сум.

➤Зарарлы предприятиеләрдә эшләүчеләргә Хезмәт министрлыгы боерыгы нигезендә бушлай сөт бирелә башлый. Совет чорында кертелгән бу норма 2020 елның февралендә юкка чыгарылган иде. Хезмәт министрлыгының тагын бер боерыгы үз көченә керә. Анда махсус туклану каралган хезмәткәрләрнең исемлеге бирелгән.

Сүзгә-сүз

duma.gov.ru

Андрей ИСАЕВ, Россия Дәүләт Думасында «Бердәм Россия» фракциясе җитәкчесе урынбасары:

Яңа уку елында мәктәпләрдәге мәгариф һәм тәрбия эшләрендә җитди үзгәрешләр булачак. Һәм бу – гаҗәп түгел. Безнең ил авыр сынауларга дучар булды, Россия һәм аның тирәсендәге дөнья бик тиз үзгәрә. Алар белән бергә мәктәп системасы да үзгәрми булдыра алмый. Гуманитар фәннәрне укыту, класстан тыш эш укучылар өчен уңай идеологик мәгънәгә ия булырга тиеш.

(«Российская газета»)

РОССИЯДӘ – COVID-19

Россиядә коронавирус инфекциясен йоктырып авыручылар саны арта. Стопкоронавирус.рф хезмәте мәгълүматлары соңгы тәүлектәге вазгыять турында сөйли.

РОССИЯДӘ
50952 очрак
91 үлем очрагы
37012 кеше сәламәтләнгән
3762 кеше хастаханәдә

ТАТАРСТАНДА
393 очрак

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Шәһәр урамында

Авылда озак кына торып килсәң, шәһәр бөтенләй ят булып тоела икән. Минем дә февральдән бирле калага аяк басканым юк иде. Урам буйлап атлап киләм менә. Үземне чит-ят итеп, бөтенләй башка дөнья, бүтән планета кешесе кебек тоям. Чынлап та, бүтән дөнья кебек инде ул. Хәтта атлап йөрешеңә кадәр үзгәрә. Авылда адымнарың бөтенләй башка төрле була бит. Син җиргә басасың, аяк астындагы җир аз гына чигенеп куя, аннан соң сиңа көч бирергә теләгәндәй этәреп җибәрә… Ул синең һәр адымыңны сизеп тора, һәр хәрәкәтеңә җавап кайтара, көч бирә. Син дә аны тоясың. Шул рәвешле ниндидер өнсез аралашу хасил була. Һәр адымың җир белән сөйләшү сыман килеп чыга. Шәһәрдә башка төрлерәк. Монда син җиргә түгел, ә асфальтка басып атлыйсың. Ул бернәрсә дә сизми, һәр адымыңны җавапсыз калдыра. Стенага борчак сипкән кебек. Саңгырау кеше белән сөйләшеп барган сыман. Хуҗасыз йортның ишеген шакыган шикелле. Шак-шок, шак-шок… Җир монда ташбака кебек, асфальт кабыгына кереп бикләнгән дә дөнья белән бәхилләшеп ята.

Кешеләр дә шул чамарак бугай. Читтән караганда, алар – үзең кебек үк җан иясе инде. Синең белән бер үк вакытта, бер үк җирдә яшиләр. Шул ук вакытта, алар параллель дөнья буйлап атлый. Кайберләре телефонына текәлеп килә дә синең дөньяңа килеп бәрелә һәм гафу үтенеп яки сүгенеп, кабат үз дөньясына кереп китә. Монда һәркемнең – үз дөньясы, күзгә күренми торган үз рельслары. Хәтта таныш-белешләрең дә күзгә карый-карый киләләр дә күрмичә үтеп китәләр. Шуңадыр инде, җәяү атлаганда да үзеңне машина тәрәзәсеннән карап барган шикеллерәк тоясың. Кая гына юнәлсәң дә, кеше белән кеше арасында күзгә күренмәс тәрәзә бар кебек.

Авылда аз гына башкачарак бит инде ул. Сине әллә кайдан күреп торалар, өлкәнрәкләре баш кагып, яшьрәкләре кулын болгап сәламли. Бик ерак арада булмасаң, килеп күрешәләр, хәл-әхвәл сорашалар. Монда син һәрвакыт күз алдында. Хәтта үзең күрмәсәң дә, сине күреп торалар. Әйтик, янымда беркем дә юк әле дип, ниндидер ахмаклык эшлисең икән, авылның икенче очында инде синең шушы ахмаклыгыңны тикшерә башлыйлар. Уйларыңа бирелеп искә алмыйча яки күрмәмешкә салышып узып китсәң, теге кеше артыңнан куып җитә:

– Син нәрсә сәлам дә бирмичә йөрисең, эре бәрәңге ашадыңмы әллә? – ди.

Шундый дөньядан соң шәһәрнең үзенчәлекләре нык сизелә икән. Йортлары биек, урамнары киң. Урам тулы кешеләр, машиналар. Яшеллек тә сөбханалла гына. Үзебезнең Казан бит. Матур инде ул, ни генә әйтсәң дә. Хурлап, гөнаһ җыярлык түгел.

Тик мин үземне чит планета кешесе сыман тоеп атлыйм. Урамнарга карап, бу планета кешеләренең ничек яшәвен күзалларга тырышам. Берни дип тә әйтеп булмый. Югары цивилизацияле дөнья инде бу, авыл белән чагыштырганда нык алга киткән. Ләкин ашыгып алга атлаганда, кайбер асыл сыйфатларны кайдадыр онытып калдырган. Ул сыйфатлар, юл буенда тузан җыеп яткан алтын балдак сыман, кайдадыр ауный торгандыр инде. Балкымыйлардыр. Алтын йөзекне балкытыр өчен дә адәм кулы кирәк.

Ә бу планета кешеләренең ничек яшәвен тиз генә күз алдына китереп булмый икән. Тик мин аларның ниндидер уртак сыйфатларын табарга тырышам. Табам да бугай. Беренчедән, монда безнең авылдагы Гаделҗан карт та, Фатыйма карчык та юк бугай. Шортик-фәлән киеп урамга чыксаң, Гаделҗан бабай:

– И улым, трусигың бик матур икән, кайдан алдың аны? Миңа да кирәк иде, – дип кеткелди торган иде. Ачуланып әйтмәсә дә, кыен булып кала, бүтән алай чыгасы килми. Ә Фатыйма карчык кыз-кыркынның һушын җибәрә:

– Кызым, күкрәкләреңнең берәрсен булса да каплабрак йөрет. Чыгып качарга да, төшеп калырга да күп сорамаслар. Әнә берсе борынлап, күлмәгеңне тишеп тә маташа бугай инде…

Шәһәр урамында кешеләрнең ботлары да, күкрәкләре дә ирекккә чыгып, дөнья күреп йөри. Гаепләп әйтүем түгел, Ходай биргән табигый матурлык бит инде. Матурлары чынлап та матур аның. Карашыңны әллә кайдан тартып торалар. Оҗмахта хур кызлары арасында йөргән шикелле тоеласың. Ә Фатыйма карчык чынлап та хаклы булган. Күкрәк мәсьәләсендә. Метро баскычыннан йөгереп менгән бер ханымныкын үзем дә чак тотып калмадым – төшеп китә дип торам.

Кием кибетләре күп инде шәһәрдә. Ризык кибетләре дә чамасыз. Урамның буеннан-буена. Аларны һәртөрле рестораннар, кафелар алыштыра. Һәм даруханәләр. Адым саен ризык сата торган җир, адым саен даруханә. Ара-тирә көнкүреш, хуҗалык тауарлары, бизәнгечләр сата торган урыннар очрый. Һәм кабат даруханә, азык-төлек… Шундыйрак тәэсир кала: бу планета кешеләре аз-маз гына киенә, чүт кенә хуҗалык эшләре белән булаша, ара-тирә бизәнә, ә төп шөгыльләре – ашау-эчү һәм чирләү. Урамдагы кибетләргә карасаң, башкача уйлап булмый. Ашыйлар да чирлиләр, дәваланалар да ашыйлар… Ашыйлар, ашыйлар, эчәләр, чирлиләр, чирлиләр, ашыйлар… – шулай яшиләр. Элегрәк китап кибетләре дә хәтсез була торган иде, хәзер аларны даруханәләр алыштырган.

Ашаган малда өмет бар, ди бит халык. Димәк, бу планетаның киләчәге зур әле… Сантый уйлардан арынып, чынбарлыкка кайтам да елмаеп куям.

Күктә – кояш, җирдә мин елмаям. Елмаерлык инде, бер карасаң… Башкалар да елмаялар икән. Елмаючылар күп.

Алар да авылдан килгәннәрдер инде.

МИҢНЕХАНОВ – ИКЕНЧЕ

tatarstan.ru

Рөстәм Миңнеханов июль – август айларында төбәк башлыкларының эшчәнлек рейтингында икенче урынга чыккан. Беренче урында – Мәскәү мэры Сергей Собянин. Тула өлкәсе губернаторы Алексей Дюмин – өченче.

Журналист, сәясәт белгече, Россия иҗтимагый палатасы вәкиле Александр Малькевич фикеренчә, Татарстан Президентының активлыгы Россия Дәүләт Советы президиумы утырышында аеруча ачык чагылган. Хәтерләсәгез, Рөстәм Миңнеханов, Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм шәһәр мохите комитеты рәисе буларак, утырышта төзелеш тармагын үстерү һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсен яңарту уңаеннан тәкъдимнәрен җиткергән иде.

– Челтәрләрнең тузуы турында Петербургта узган халыкара икътисад форумында да сөйләштеләр. Россия Президенты Владимир Путин да торак-коммуналь хуҗалык тармагын яңартуның комплекслы программасын тормышка ашырырга кирәклеген искәртте. Бу программаның кирәклеге күптән билгеле, аның бик зур капитал таләп итүе дә көн кебек ачык. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, ул күпфатирлы торак йортларны төзекләндерү программасы кебек үк нәтиҗәле булачак. Аны тормышка ашыру турында карар 2007 елда нәкъ менә Казанда, Россия Дәүләт Советы президиумы утырышында кабул ителгән иде, – ди белгеч.

Александр Малькевич фикеренчә, халыкара мәйданда катлаулы вазгыять урнашкан шартларда Татарстан җитәкчелегенең чит ил партнерлары белән актив рәвештә эшләүне дәвам итүе дә игътибарга лаек.

– Шушы чорда Таҗикстан, Иран, Төркия, Мьянма вәкилләре белән нәтиҗәле очрашулар узды. Республиканың халыкара мәйдандагы активлыгын «Казан – Ислам хезмәттәшлек оешмасының Яшьләр башкаласы» программасы кысасында көтелгән чаралар да раслый. Август аенда биредә мөһим чара – Ислам хезмәттәшлек оешмасы илләренең яшьләр эшләре һәм спорт министрлары катнашында зур яшьләр саммиты узды, – ди Малькевич.

Моннан тыш, белгеч махсус хәрби операция шартларында Рөстәм Миңнехановның икътисад мәсьәләләренә аерым игътибар бирүен, шул рәвешле халык тормышына йогынты ясарлык карарлар кабул ителүен билгеләп үткән. Александр Малькевич фикеренчә, Татарстан Президентының урып-җыю эшләре белән кырга чыгып танышуы, хезмәт кешесенә мөнәсәбәте дә игътибарга лаек. Аның Татарстанда яшәүче халыкларның бәйрәмнәрен зурлавы исә күпмилләтле республикада тынычлык һәм татулыкны раслый.

	Төбәк башлыгы	Төбәк
1	Сергей Собянин	Мәскәү
2	**Рөстәм Миңнеханов**	**Татарстан Республикасы**
3	Алексей Дюмин	Тула өлкәсе
4	Рамзан Кадыйров	Чечня Республикасы
5	Андрей Воробьев	Мәскәү өлкәсе
6	Александр Дрозденко	Ленинград өлкәсе
7	Айсен Николаев	Саха Республикасы
8	Дмитрий Артюхов	Ямал-Ненец автоном округы
9	Евгений Куйвашев	Свердловск өлкәсе
10	Сергей Цивилев	Кемерово өлкәсе

ИКЪТИСАД НИГЕЗЕ

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәрләре көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәрләре!

Кадерле тармак ветераннары!

Нефть һәм газ сәнәгате – Татарстан икътисады нигезе, талантлы белгечләрне, инновацион технологияләр, техниканы тартып тору үзәге. Һөнәри эшчәнлегегез өлкәсе, күп кенә катнаш тармаклар өчен этәргеч көчкә әйләнеп, республиканың энергетик, индустриаль, фәнни мөмкинлекләрен ныгыту һәм халыкның тормышын яхшырту өчен ышанычлы нигез булып тора. Хезмәтегез нәтиҗәсендә заманча производстволар ачыла, яңа эш урыннары, торак төзелешен үстерү өчен шартлар булдырыла.

Бүген, геосәяси вазгыятьнең катлаулы булуына карамастан, нефть чыгаруның нәтиҗәсен арттыру, яңа сәнәгать объектларын магистраль газ белән тәэмин итү, социаль газлаштыру кысаларында торак йортларны газга тоташтыру кебек Татарстан Республикасы өчен стратегик проектлар гамәлгә ашырыла, импортны алыштыру һәм нефть производстволарының экологик иминлеген ныгыту бурычлары хәл ителә. Республика нефтьчеләре һәм газчыларының көндәлек тырыш хезмәте һәм югары дәрәҗәдә җаваплылыгы нәтиҗәсендә зур уңышларга ирешелә.

Һөнәри бәйрәмегез – Нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәрләре көне уңаеннан сезгә һәм гаиләләрегезгә нык сәламәтлек, иминлек телим! Барлык эшләрегездә уңышлар насыйп итсен!

ЧИТТӘГЕГӘ ЫШАНЫЧ ЮК

Җиде кат үлчә, бер кат кис! Белгечләр Казахстаннан машина кайтартырга теләүчеләргә шундый киңәш бирә. Ник дигәндә, чагыштырмача арзан бәясенә кызыгып алып кайткан машина бик күп кыенлыклар да китереп чыгарырга мөмкин икән. Бу хакта журналистларга Идел буе таможня идарәсенең таможня контролен оештыру хезмәте башлыгы вазыйфаларын башкаручы Александр Преорчук сөйләде.

Ул китергән саннардан аңлашылганча, быел Идел буе федераль округына Казахстаннан 2 меңнән артык «тимер ат» алып кайтканнар. Чагыштыру өчен: 2021 елда бу күрсәткеч 88 генә булган. Александр Преорчук фикеренчә, саннар артуга, нигездә, Россиянең машина базарындагы кыенлыклар, Казахстанда исә автомобильләрнең чагыштырмача очсызрак булуы сәбәпче.

Әмма арзан бәягә кызыгып кына ашыгыч карарлар кабул итмәскә киңәш итә ул. Ник дигәндә, читтән кертелгән машина бик күп кыенлыклар да китереп чыгарырга мөмкин. «Билгеле булганча, Белоруссия, Әрмәнстан, Казахстан, Кыргызстан һәм Россия бердәм таможня территориясенә керә. Евразия икътисади союзы товарлары әлеге ил территорияләре буйлап иркен хәрәкәт итә ала. Алардан таможня декларациясе, таможня пошлинасы да таләп

ru.pinterest.com

ителми. Әмма бу илләрдә, әйтик, шул ук Казахстанда әлеге статуска ия булмаган товарлар – шул ук машиналар да булырга мөмкин. Таможня органнары өчен андый товарлар чит ил товарлары санала», – ди Александр Преорчук.

2015 елның октябрендә төзелгән килешү нигезендә Казахстанга таможня берлеге тарафыннан билгеләнгән таможня тарифыннан күпкә түбәнрәк булган ставка белән өченче илдән товарлар кертелә ала. Әлеге килешү нигезендә Казахстан шушы республика территориясендә генә кулланылырга тиеш булган транспорт чараларын да билгели ала. Алар белән шушы җирлектә яшәүче кешеләр генә идарә итәргә хокуклы. Машинаны чит төбәкләргә Казахстанда даими яшәүче кешеләр генә алып чыгарга мөмкин. Казахстанда яшәмәүче кешеләргә мондый машиналарны Россиягә кертү тыела.

– Юридик затлар бу машиналарны Россиягә кертә алсын өчен, аларга Казахстан территориясендә өстәмә пошлина түләргә туры киләчәк. Әйтик, «тимер ат» Казахстанда 0 процент белән рәсмиләштерелгән булса, аның өчен машина бәясенең 15 проценты күләмендә өстәмә пошлина түләргә туры киләчәк. Бу машина да берничә йөз мең сумга кыйммәткәрәк төшәчәк дигән сүз. Шуңа күрә Казахстаннан машина кайтарту арзанга төшә диючеләр ялгыша, – ди Александр Преорчук.

Шуңа күрә белгечләр Казахстаннан машина сатып алыр алдыннан машинаны шушы республика территориясендә үк яхшылап тикшертергә киңәш итә. Ул машина кайда, нинди шартларда теркәлгән? «Әгәр ул түбән процент ставкасы белән рәсмиләштерелгән булса, иң элек Казахстанда бу машинаның статусын үзгәртерлек чаралар күрелергә тиеш. Юкса бу автомобильне чик аша чыгарганда да, исәпкә куйганда да проблемалар килеп чыгачак», – ди Александр Преорчук.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КЫЙММӘТЛЕ ТОЯКЛАР

vk.com

Яшәеш

Татарстанда кыргый хайваннарга үрчү өчен барлык шартлар да тудырылган. Республикада мараллар һәм тимгелле боланнарның саны аеруча тиз арта. 2015 елда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тәкъдиме белән урманнарга 70 болан җибәргән булсалар, хәзер аларның саны 500гә җиткән. Тагын да күбәеп китсәләр, ауга рөхсәт бирә башлаячаклар. Бу хакта Министрлар Кабинетында узган очрашуда Татарстанның биоресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе Федор Батков җиткерде.

– Бездә 81 төр хайван яши. Аларның кайберләрен үрчетәбез, артыгын киметәбез. Җәнлекләрнең байтагы юлларда транспорт бәрдерү аркасында үлә. Монысыннан инде котылып булмый. Быелның соңгы 8 аенда гына да Татарстан юлларында 105 шундый очрак теркәлеп, 106 җәнлек һәлак булды, – ди Федор Батков. – Килгән зыянны бәрдерүченең иминият оешмасы каплый. Ә менә күп кенә машина йөртүчеләр авария урыныннан качып китә. Быел 48 кеше шулай эшләгән. Машина йөртүчеләр төнге вакытларда аеруча тизлеген киметеп йөрсен иде.

Күптән түгел бер туганыбыз юл аркылы чыгып барган пошины бәрдергән иде. Үзе күрми калдым дип аклана. Дөрестән дә, төнлә кайбер урыннарда ут булмау харап итә икән. «Поши баласын бәрдерткәнемне сизми дә калдым. Тизлегем дә зур түгел иде. Әллә каян килеп чыкты ул. Кызгандым инде. Әнисе дә кире борылып килде. Ул да елады кебек. Мин дә. Миңа поши бик кыйммәткә чыкты. Машинама да зыян килде. Шактый вакыт рульгә дә утыра алмадым. Бу очрак миңа гомерлеккә сабак булды», – ди Резеда Харисова.

М12 тиз йөрешле автотрассасында хуҗалык маллары һәм кыргый җәнлекләр өчен чыгып йөрергә махсус тоннельләр ясала. Федор Батков, бәлки, шуннан соң җәнлекләрне саклый алырбыз, дигән фикердә.

Татарстанның биологик чыганакларын акчага әйләндереп карасаң, 2 миллиард сумнан артып китә. Федор Батков сүзләренә караганда, безнең урманнарда кыр кәҗәсе, пошилар бик яхшы үрчи икән. Быел пошилар саны 1535кә артып – 13635, кыр кәҗәсе исә 2529га үрчеп, 12708 булган. Ә менә Африка чумасы аркасында кабаннар саны көннән-көн киметелә икән. 2020 елда алар 6 мең баш булса, быел 1225кә калган. Урмандагы җәнлекләрнең исәбен кыш көне алалар. Кар өстендәге эзләренә карап санап чыгалар. Быел аучылар кыш көне хайваннар исәбен алыр өчен 18 мең чакрым ара узган. Әнә шул рәвешле җәнлекләр саны билгеле була. Кыш көннәрендә аеруча кабаннар «эзенә төшү» тиз икән.

Республикада 6 миллион 309,4 мең гектар аучылык җирләре бар. Татарстан мәйданының 93 проценты дигән сүз бу. 5 тыюлыкта аучылык катгый рәвештә тыела. Узган ел 37 мең кешегә ау өчен рөхсәт бирелгән. Әлегә аучылар кабаннар санын киметү белән мәшгуль.

Комитет рәисе Африка чумасы хакында бик тәфсилле итеп сөйләде. Кабаннар аша йорт хайваннарына да зыян килә, ди.

– Республикада 99 ау хуҗалыгы эшли. Аларның барысы да кабаннарны киметү кирәклеге хакында белә. Без урманнардагы берничә кабан дуңгызын атып, анализын карадык. Аларда авыру юк, – ди Федор Батков. – Әмма кайбер районнарда Африка чумасы табылган йорт дуңгызлары да бар бит. Мамадыш, Алексеевск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарында шунлыктан кабаннарга ау бара. Бу районнарда Африка чумасының 9 очрагы теркәлгән. Шуларның алтысы – хуҗалык дуңгызларында. Безнең максат – кабаннар санын киметү. Әлегә аучылар үлән комачау иткәч, аларны ата алмый. Әмма без төнлә басуларда йөргән кабаннарны аулар өчен дә барлык мөмкинлекләрне тудырдык. Без азык-төлек сәнәгатенә зыян китермәскә, малларны сакларга тиеш.

Журналистлар арасында кабаннарны аз кала дип тә борчылучылар булды. Әмма белгечләрнең аларга җавабы әзер: Татарстанда кабаннар тиз үрчи. Аларга азык та җитәрлек. Кабан дуңгызы чир тарата дисәләр, бүрене ник аталар? Элек-электән урман санитары дип йөртә идек бит. Баксаң, бүреләр үзләре дә күп үрчеми икән. Элек авылларда үләт базлары булганда, фермалар гөрләп эшләгәндә, алар күп булган. Хәзер мал үләксәләрен махсус утильләштерәләр. Шуңа да бүреләр бездә бармак белән генә санарлык икән. Федор Батков сүзләренә караганда, алар безгә Чувашия Республикасыннан, Самара, Ульян өлкәләреннән керәләр. Әмма аларга үрчеп китәргә ирек бирмиләр. Аучылар шундук юк итә. Бүреләр беткәч, кыргый этләр хайваннарга ташланмасмы соң? Очрашуда әлеге сорау да калкып чыкты.

– Этләрне ата алмыйбыз. Аларны тотып, приютларга алып китәргә генә ярый. Минем белүемчә, һәр район хакимиятендә этләр проблемасы хәл ителә. Алардан кыргый җәнлекләргә зыян булыр дип уйламыйм, – ди Федор Батков.

Исегезгә төшерәбез: һәр җәнлекне аулауның үз вакыты, ау мылтыгына да рөхсәт кирәк. Әгәр үз белдегең белән ауга йөрисең икән, бик күп күләмдә штраф салына. Республикада соңгы 8 айда 502 хокук бозучы ачыкланган, 255 кеше ау кагыйдәләрен бозган. Аларга 22 кисәтү ясалган. 11 ау коралы алынган. 68 җинаять эше ачылган. Кагыйдәне бозучыларга барлыгы 3 миллион 174 мең сум штраф түләттерелгән.

– Күп очракта браконьерлар тыюлыкларга да ауга килә. Әле соңгы вакытта Димитровград шәһәреннән килгән кешеләрне тоттык. Ау өчен 20 мең сумга рөхсәт аласы урынга, аларга 250 мең сум штраф түләргә һәм табигатькә зыян салган өчен 450 мең сум чыгарып салырга туры килде. Шуңа да ау яратучылар алдан хәстәрен күрсен иде, – ди ул.

Очрашуда «Түбән Кама» тыюлыгы хакында да сүз булды. Бу хакта Алабуга районы башлыгы урынбасары Олег Колпаков видеоэлемтә аша сөйләде. Аның сүзләренә караганда, Алабуга районында «Кызыл китап»ка кертелгән кыргый хайваннар да күп очрый икән. Алар да үзләрендә боланнар үрчетәләр. Быел аларның саны 800 башка җиткән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ГАЛӘМГӘ ЮЛ АРЧАДАН БАШЛАНА

Ният

«Җиһангирлар» инициатив төркеме эшчәнлеге яңа этап башлады. Аның җитәкчесе Хәлил Гайнетдинов мәктәпләр, уку йортлары белән элемтәне тагын да ныгыту максатыннан яңа программа тәкъдим итте.

Җиһан безне берләштерә

Моның өчен юкка гына Арча педагогия көллияте сайлап алынмады. Беренчедән, бу уку йорты бик актив, балаларны тәрбияләүдә файдасы булган һәр яңалыкны тиз арада кертү яклы булса, икенчедән, район башлыгы Илшат Нуриев җиһангирларга ярдәм итәргә һәрвакыт әзер тора. Бу очрашуда да ул әлеге тәкъдимне хуплап кына калмады, Җиһангирлар паркы проекты турында да сүз кузгатты.

– Космос ул – һәркемне кызыксындыра торган өлкә, яшь буынны ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләр өчен менә дигән җирлек. Без барыбыз да – Гагаринга сокланып, космонавт булырга хыялланып үскән кешеләр. Космос, җиһангирлар хәрәкәте белән янып-көеп йөргән Хәлил Шәйхнуровичка сокланып карыйм. Үзе дә тик тормый, безгә дә тынгылык бирми. Җиһангирлар паркы турында да күптән сөйләшәбез. Эшкә тотынырга вакыт җиткәндер дип уйлыйм, – диде ул.

Беррәттән Татарстанның беренче космонавты Сергей Рыжиковны һәм «йолдызлы» шәһәрдә эшләүче Татарстан егетләрен кунакка чакыру турында да фикерләштеләр. Күрсәтерлек әйберләр дә бар. 2016 елның 19 октябрендә Бөгелмә егете Россиянең (СССРның) 121 нче космонавты булып, беренче тапкыр галәмгә юл тотты. Арчалылар һәрвакыттагыча бу вакыйганы да читтә калдырмадылар. Якташыбыз 11 сәгать 5 минут 14 секундта галәмгә юл тотты. Нәкъ шул мизгелдә стадионда Җиһангирлар аллеясына нигез салынды. Татарстанның беренче космонавты хөрмәтенә стела да куелды.

Яңа программа буенча быел көллияттә эш башланган да инде.

– 2022–2023 уку елы планына космос өлкәсен өйрәтүне аерым бер бүлек итеп керттек. Көллият каршында гимназия сыйныфлары, балалар бакчасы бар, база буларак, 6 нчы мәктәп белән дә тыгыз элемтәдә яшибез. Космос өлкәсе барысын да нык кызыксындыра. Без инде моңа кагылышлы чараларны «Җиһангирлар» инициатив төркеме белән берлектә күптәннән үткәреп киләбез. Әмма билгеле бер системага салынмаган иде әле. Тәҗрибә уңышлы килеп чыкса, аның шулай булуына шигебез дә юк, концепция төзеп, Мәгариф министрлыгы ярдәме белән башка мәктәпләргә, уку йортларына да тәкъдим итәргә уйлыйбыз, – диде бу җәһәттән көллият директоры Гөлнара Гарипова.

Мөмкинлекләр бар

Хәлил Гайнетдинов Байконурда хезмәт иткән. Сирәк-мирәк кенә булса да кулына кылкаләм тоткан егетне данлыклы космодром тарихына кагылышлы документлар белән эшләргә чакыралар. Менә шунда ул җиһан белән чын-чынлап кызыксына башлый да инде. Килеп җитә бер вакыт, мавыгуының чын икәнен аңлагач, шушы төркемгә космос өлкәсенә кагылышлы булган фикердәшләрен җыя башлый. Алар арасында фән эшлеклеләре дә, космос тармагында бүген эшләүчеләр дә, ветераннар да бар. Мәгариф, мәдәният хезмәткәрләре, журналистлар, студентлар, мәктәп балалары да бик яратып йөри алар оештырган очрашуларга. Космос өлкәсе буенча белгечләр Урал Закиров, Альберт Саттаров, Айдар Бикмучев, Фәрит Әюпов кебек белгечләрне тыңлау – үзе бер дөнья. Хәлил Гайнетдинов Ким Шакиров белән бергә «Сезне космос көтә, җиһангирлар!» дип аталган китап та иҗат итә. Анда Советлар Союзы һәм Россиядәге космик проектларны төзүдә катнашкан татарлар һәм татарстанлылар турында барлык мәгълүматлар бар. Китапка 700 фамилия кергән, шуларның 400е – татарныкы. Бу космос өлкәсендә хезмәт куючы милләттәшләребезнең күплеген күрсәтә. Казан – бүген дә Россиядә иң зур аэрокосмик үзәкләрнең берсе. Татарстан исә инновацион үсеш буенча алдынгылардан санала. Димәк, «йолдызлы» эшне дәвам итү өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар.

Чаң

Ни өчен әле җиһангирлар мәктәпләргә, уку йортларына галәм темасын кертү турында чаң суга? Бу сорауга җавап бирү өчен Хәлил Гайнетдинов ерактан урап килде.

– Билгеле булганча, Россия, Советлар Союзының дәвамчысы буларак, космосны беренче ачучы булып санала. Константин Циолковский галәмне үзләштерүнең кирәклеген, мөмкинлеген һәм ысулларын фәнни яктан дәлилли. Сергей Королев аның идеяләрен беренче тапкыр тормышка ашыра. Ул коллектив белән ракеталар, ясалма иярченнәр, орбитага чыгып, Җир тирәли әйләнү һәм беренче космонавтның галәмгә очуы өчен корабльләр төзи. Юрий Гагарин беренче булып космик корабльдә Җир шарын әйләнә. Валентина Терешкова – галәмгә очкан иң беренче хатын-кыз. Алексей Леонов беренче булып ачык космоска чыга. Хатын-кыз космонавтлардан Светлана Савицкая шул ук батырлыкны кабатлый. Бу казанышлар искиткеч һәм аларның барысы да халык хәтеренә уелып калган. Әмма алар барысы да Советлар Союзына бәйле.

Юрий Гагарин космоска очканнан соң 61 ел үткәч тә, без Россияне космос өлкәсендә лидер дип уйлыйбыз. Ни кызганыч, бу дөреслеккә туры килми. Бүгенге Россия дөньядагы космик державалар арасында АКШ һәм Кытайдан кала өченче урынны гына били. Һиндстанда да космик индустрия көчле үсеш алган. СССР таралганнан соң, илебезнең оборона сәнәгате комплексы зур югалтулар кичерде. Әмма юкка чыкмады, аягында басып кала алды. Бүген безнең төп көндәшләребез – АКШ, Кытай, Европа берлеге. Япония, Канада, Һиндстан, Иран һәм Бразилия үкчәгә басып килә. Ә бит бу калышуда төп факторларның берсе – кадрлар әзерләү барышында урта мәктәпләрдә пәйда булган кимчелекләр. Бу турыдан-туры совет укыту системасын юк итүгә, физика һәм математика фәннәрен укыту буенча җитешсезлекләргә килеп төртелә.

Әнә шул бушлыкны тутырырга тырыша да инде «Җиһангирлар» төркеме. «Гагарин белән 108 минут бергә» проекты, Арча радиосындагы атналык «Җиһан серләре» тапшырулары, «Гагарин көне» бәйрәме, «Гагарин ярминкәсе», «Гагарин бәлеше» бәйрәме, «Җиһангирлар паркы», «Җиһангир бакчалары һәм урманнары», төрле-төрле башка чаралар – барысы да укучыларны кызыксындыруга йөз тота. Бүгенге программа исә бу чараларны Татарстанга гына түгел, Россия төбәкләренә җәелдерүне дә күздә тота.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «ТАНЕКО» акционерлык җәмгыятенең сәнәгать куркынычсызлыгы идарәсе сәнәгать куркынычсызлыгына производство контроле бүлегенең сәнәгать куркынычсызлыгы буенча әйдәүче инженеры **Хуҗиева** Винера Кашафетдин кызы **«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале** белән бүләкләнде.

***

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефтегазпереработка» идарәсе төзекләндерү-механика һөнәрханәсенең электр һәм газ белән эретеп ябыштыручысы **Зәкиҗанов** Рамил Расих улына **«Татарстан Республикасының атказанган газ тармагы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте Татарстан геология, нефть эзләү идарәсенең запасларны хисаплау буенча проектлау офисы 1 нче запасларны хисаплау төркеменең проект баш инженеры **Акчурина** Надежда Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган геологы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе катлау басымын саклау цехының катлау басымын саклау операторы **Әхмәтов** Фәрит Фаикъ улына, «Геология, нефть эзләү буенча тикшеренү үзәге» акционерлык җәмгыятенең җитештерү-техник бүлеге башлыгы – баш технологы **Ильясов** Илгиз Тулпар улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Бизнеска хезмәт күрсәтү үзәге сәнәгать һәм экология иминлеге үзәге җитәкчесе **Исламов** Ренал Рифкать улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе нефть һәм газ чыгару департаментының нефть һәм газ чыгару идарәсе баш эксперты **Латфуллин** Рөстәм Руслан улына, «Кара Алтын предприятиесе» ябык акционерлык җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары – җәмгыятьнең баш инженеры **Саттаров** Айдар Илдар улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе ятмаларны үзләштерү департаменты операция эшчәнлеге бүлегенең Лениногорск территориясе буенча төркемнең 1 категорияле белгече (скважиналарны геофизика ягыннан тикшерү буенча) **Хәлиуллин** Илгиз Әхмәтмидхәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Түбән Кама механика заводы» акционерлык җәмгыятенең җыю производствосына хезмәт күрсәтү цехы автоматлаштыру чаралары һәм технологик җиһазлар приборлары буенча электромеханигы **Баранов** Владимир Александровичка, «ТАНЕКО» акционерлык җәмгыяте генераль директорының техник хезмәт күрсәтү һәм инжиниринг буенча урынбасары хезмәте электр җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны төзекләндерү хезмәтенең нефть продуктлары өчен резервуар парклары электр җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны төзекләндерү участогы электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтеры **Паранин** Валерий Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Минзәлә район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы урынбасары – эпизоотиягә каршы эш буенча ветеринария табибы **Хайруллова** Гөлнара Фәнис кызына, «Апас район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең Югары Аккуҗа ветеринария участогы мөдире – ветеринария табибы **Хәлилов** Рафил Равил улына, «Балык Бистәсе район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең Балык Бистәсе ветеринария участогы мөдире – ветеринария табибы **Якупов** Җиһанша Минша улына, «Евростиль» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзү эшләре җитәкчесе **Шәрифуллин** Артур Илнур улына, «АЛЬПАРИ» хәйрия фонды директоры **Гыйлаҗева** Наталья Александровнага, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең инновацион үсеш идарәсе башлыгы **Дыганов** Антон Георгиевичка, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика суд-медицина экспертизасы бюросы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе хезмәткәрләре: хуҗалык бүлеге автомобиль йөртүчесе **Алиуллов** Рифат Ринат улына, хуҗалык бүлегенең хуҗалык мөдире **Әхмәтшин** Артур Рөстәм улына, мәетләргә суд-медицина экспертизасы уздыру бүлеге фельдшер-лаборанты **Нотфуллина** Айсылу Мосавир кызына, мәетләргә суд-медицина экспертизасы уздыру бүлеге табибы – суд-медицина эксперты **Петров** Валерий Ивановичка, мәетләргә суд-медицина экспертизасы уздыру бүлеге табибы – суд-медицина эксперты **Сираҗетдинов** Марат Ринат улына, учреждениенең башлыгы **Тимерҗанов** Марат Исмәгыйль улына, медицина-криминалистика бүлекчәсе табибы – суд-медицина эксперты (эш урыны – Чаллы шәһәре) **Язик** Валерий Леонидовичка, мәетләргә суд-медицина экспертизасы уздыру бүлегенең Алабуга районара суд-медицина бүлекчәсе табибы – суд-медицина эксперты **Вострокнутова** Екатерина Владимировнага, мәетләргә суд-медицина экспертизасы уздыру бүлегенең Баулы районара суд-медицина бүлекчәсе табибы – суд-медицина эксперты **Галиев** Наил Равил улына, Чаллы филиалының зыян күрүчеләргә, гаепләнүчеләргә һәм башка затларга экспертиза уздыру бүлекчәсе мөдире – табибы – суд-медицина эксперты **Ермолаев** Олег Михайловичка, Чаллы филиалының мәетләргә суд-медицина экспертизасы уздыру бүлекчәсе мөдире – табибы – суд-медицина эксперты **Никитин** Тимур Анатольевичка, мәетләргә суд-медицина экспертизасы уздыру бүлегенең Бөгелмә районы суд-медицина бүлекчәсе мөдире – табибы – суд-медицина эксперты **Шаһиев** Илдар Илгизәр улына, «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе җитәкче-урманчысы **Абдуллин** Наил Зөфәр улына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының стратегик үсеш бүлеге башлыгы **Гайнова** Регина Әсхәт кызына, Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе җитәкчесе **Галявов** Рөстәм Әсфан улына; «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе радиология бүлекчәсе мөдире – табиб-радиологы **Җиһаншина** Лилия Фәрит кызына; шәхси эшкуар **Лоханина** Әлфия Әнәс кызына, «Сәйдәшев исемендәге авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры **Сәйфуллин** Азат Рәсим улына, «Аксу-Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районындагы филиалы директоры **Шәрәпов** Газим Мөнир улына, «Чаллы шәһәре көрәш федерациясе» җирле иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Фәйзуллин** Рәкыйп Нәҗип улына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Әлмәт районы һәм Әлмәт шәһәре территориаль бүлекчәсе экспертиза бүлеге башлыгы **Хисаметдинова** Фәйрүзә Сәйдел кызына, «Россия суд эшчәнлеге дәүләт университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Казан филиалы директоры (Казан шәһәре), Татарстан Республикасы Югары Судының отставкадагы судьясы **Шәрифуллин** Рамил Әнвәр улына, **Гатин** Рөстәм Равил улына, Түбән Каманың «След» эзләү-коткару иреклеләр отряды волонтеры **Емельянов** Виталий Викторовичка, «Казан медицина көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе студенты **Кайсина** Мария Марат кызына, Татарстан Республикасының «Татинвестгражданпроект» баш территориаль проект-тикшеренү фәнни-җитештерү фирмасы» дәүләт унитар предприятиесе генераль директорының архитектура мохите дизайны буенча урынбасары **Вәлиева** Елена Анатольевнага, «Евростройхолдинг+» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җитештерү-техник бүлеге башлыгы **Камалетдинова** Резеда Рифкать кызына, «Евростройхолдинг+» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзелеш буенча директоры урынбасары **Лебедков** Денис Евгеньевичка, «ПСК Гранит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзү эшләре җитәкчесе **Левашин** Дмитрий Юрьевичка, «Реконструкция һәм Үсеш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзү эшләре җитәкчесе **Леонтьев** Александр Андреевичка, «ПСК Гранит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры **Мисбахова** Ильмира Дамир кызына, «Реконструкция һәм Үсеш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзү эшләре җитәкчесе **Мөхәммәдуллин** Элдар Илдус улына, Татарстан Республикасының «Татинвестгражданпроект» баш территориаль проект-тикшеренү фәнни-җитештерү фирмасы» дәүләт унитар предприятиесенең 6 номерлы архитектура-планлаштыру остаханәсе инженеры **Сираҗев** Рамил Вагыйзь улына, «Ваттсла» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең электромонтажлау участогы бригадиры **Федотов** Роман Вячеславовичка, «Ваттсла» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Чепарухин** Дмитрий Леонидовичка, «Реконструкция һәм Үсеш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең участок башлыгы **Чигаров** Александр Анатольевичка; «Альто Вижн» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Булатов** Максим Борисовичка, «Технократия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең идарәче партнеры **Ганиев** Булат Айнур улына, «Реконструкция һәм Үсеш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте хезмәткәрләре: куркынычсызлык хезмәте башлыгы **Акманов** Петр Алексеевичка, төзү эшләре җитәкчесе **Иванов** Олег Михайловичка **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

***

Татарстан Республикасының «Чаңгы ярышлары һәм биатлон федерациясе» төбәк җәмәгать оешмасы спортчылары: **Вәлиева** Рәмилә Әмир кызына, **Муравьева** Жанна Никандровнага **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Түбән Кама нефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләре: автоматлаштыру үзәгенең технология цехларында физика-химия анализы җиһазларын эшләтү һәм төзекләндерү цехының контроль-үлчәү приборлары һәм автоматлар слесаре **Андреев** Николай Алексеевичка, этилен заводының арадаш складлар, тиз кабынучан сыеклыклар, сыегайтылган газ һәм калдыкларны термик эшкәртеп чистарту, пропиленны кабул итү, саклау, төяп җибәрү цехының суны парга әйләндереп корыту аппаратчысы **Гарифуллина** Гөлгенә Галимҗан кызына, баш технолог урынбасары **Гыйлаева** Гүзәл Вәнур кызына, изопрен-мономер җитештерү заводының катализаторлар җитештерү цехы катализаторлар әзерләү аппаратчысы **Кузьмин** Сергей Анатольевичка, бутил каучук заводының полимерлаштыру, газсызлаштыру, кайтарма продуктларны ректификатлау цехы кудырту аппаратчысы **Мальцева** Тамара Михайловнага, җиһазларны төзекләндерү үзәгенең пластик заводы җиһазларын төзекләндерү цехы слесаре-төзекләндерүчесе **Маркелов** Павел Павловичка, фән-технология үзәгенең тикшеренү аналитика лабораториясе химик анализ буенча өлкән лаборанты **Мөхетдинова** Әлфия Зәки кызына, техник контроль идарәсенең полистирол пластик һәм полиолефиннар җитештерүгә техник контроль бүлеге физика-механика сынаулары лаборанты **Нифонова** Римма Альберт кызына, стирол һәм полиэфир сумалалар җитештерү заводының пропиленны эпоксидлау цехы башлыгы **Сибгатуллин** Ильяс Илдус улына **«Татарстан Республикасының атказанган химигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Коткаручы

Минем авылдан китүемә инде байтак вакыт, әмма Казан белән Нурлат төбәгендәге Яңа Иглай арасындагы юлга тузан кундырганым юк диярлек. Газиз әнием, туганнарым авылда яши. Моннан бер атна чамасы элек тә изге ният белән юлга кузгалдым. Башкалабызны чыгуга ук табигать хозурлыгына чумасың, искиткеч гүзәллек үзенә тарта: сокланасың, уйланасың, күзгә яшь тулган чаклар да була. Бу юлы, ни хикмәт, янгын сүндерү машинасы каршы алды һәм күңел «дөрт» итеп китте.

Ни аяныч, авылга кайтуның икенче кичендә «Рузалияләрдә янгын» дигән коточкыч хәбәр таралды. Йорт-җирләре белән янәшәдәге печән өеменә ут капкан икән. Афәт урынына иң беренчеләрдән булып «Беларусь» тракторы белән Рушан Сатдаров килеп җиткән һәм тракторга көйләнгән җайланмасы ярдәмендә утлы печәнне хәвеф-хәтәрсез урынга ташый башлаган. Өем дөрләп яна, ә ул ут эченә ыргыла. Батырлык димичә, ни дисең моны?! Бер мәлдә тракторга да ут каба, аны җәһәт кенә сүндереп өлгерәләр һәм Рушан батырлыгын дәвам итә.

Рушанга ярдәмгә башка авылдашлар, янгын сүндерүчеләр дә озак көттерми һәм алар иртән яктырганчыга кадәр уяулык күрсәтәләр. Халык печәнне мулдан әзерләгән. Рушан батырлык күрсәтмәгән булса, мондый хәлнең азагын күз алдына китерү дә коточкыч. Яңа Иглай халкы иң беренче чиратта Рушанның үзенә, кешелеклелек, ярдәмчеллек, батырлык сыйфатлары тәрбияләгән әти-әнисенә – Зариф белән Миңнегөлсемгә бик рәхмәтле. Аллаһы Тәгалә исәнлек-саулыктан аермасын, бәла-казалардан сакласын, һәркайсыбызга бәхетле тормыш насыйп итсен! Бердәм, тату һәм дини безнең Яңа Иглай халкы. Мәчет тутырып, яше-карты намазга йөри. Дөньялыкны да, динне дә тигез күреп, матур гомер кичерәләр, бу инде бәла-казаларга да ныклы киртә.

Разия ӘХМӘДИЕВА

«ҮЗЕБЕЗНЕҢ ЗИРАТНЫ КАРА»

Уйлы күңел уйлана

Соңгы елларда югалтулар күп булды. Танылганнар да китә, танылмаганнар да... Танышлар, таныш түгелләр дә... Араларында яшьләрнең күп булуы йөрәкне телә.

Бер айлап элек кинәт вафат булган, берничә буын кешеләренең яраткан җырчысы, халык яратып, «легенда» дип йөртүче Юрий Шатуновның үлемен нигәдер авыр кичердем. Бик тә кызгандым үзен. Шушы хакта бер танышыма әйткәч: «Нигә аны гына җәллисең? Әнә күпме танылганнар китте. Үзебезнең татар дөньясында гына да күпме югалту», – диде. «Фанаты идеңме әллә?» – дип тә өстәде. «Нинди фанаты, – мин әйтәм. – Популяр берничә җырын белә идем, бер тапкыр язмада да концертын караганым булмады. Менә үлгәннән соң соңгы концертын карадым».

– Алайса, нәрсәгә кызгандың? – ди бу.

– Бигрәк яшь бит, тормышта бик күпне күргән, барысына ирешеп, сөенеп кенә яшисе урында, – дим.

– Андыйлар бер ул гына түгел, – дип, мине чынбарлыкка кайтарырга тырышты танышым. Башка сүз көрәштерү мәгънәсез икәнне аңладым да, үз уйларымның хаклыгына тамчы да шикләнмәсәм дә, сүзне башкага бордым. Ә бит күпләр көнләшерлек популярлык һавадан төшмәгән бу җырчыга. Соңгы концертында да әнә тамашачыга бөтен энергиясен бирә. Ике көннән вафат буласы кеше дип һич уйламассың. Үлем каш белән күз арасында гына, диләр. Бу яктан да уйландыра аның язмышы.

Шуңа охшаш хәл тагын булды әле бу арада. Күптән инде Балтачның теге очына – зираты урнашкан якка барганым булмаган икән. Мин күргәндә зиратның моннан ике-өч дистә еллап элек зурайтылган өлешендә шактый буш җире бар иде. Сүз уңаеннан, биредә каберләрне искиткеч тәртип белән урнаштыралар, рәт аралары да тип-тигез, яңа каберлекләргә агачлар да утырттмыйлар. Бөтен бистәгә бер зират булса да, каберләр күп сыйды, аларның артканы әллә ни сизелмәгән дә иде. Күптән түгел күреп, гаҗәпкә калдым: юклы-барлы бер ел эчендә зиратның бу өлеше коймага кадәр тулган... Баксаң, инде элекке өлешендәге буш урыннарга кабат күмә башлаганнар икән.

Бер авылдашыма шушы хәлне гаҗәпсенеп сөйләгән идем, «Үзебезнең зиратны кара», – диде. Әйе, бездә дә соңгы елларда вафат булучыларның саны шактый зур. Кечкенә авыл димәссең. Читтән «кайтучылар» да бар. «Ковид» та үз эшен эшләде, кинәт китеп баручылар да булды. Күбесе әле тормыш көтәрлек яшьтә иде...

Үлем яшькә-картка карамый шул. Моннан биш ел элек, авылыбызда мәчет ачылганда, имам итеп өлкәнрәк яшьтәге абыйны куярга теләдек. «Ул олы кеше инде, яшәгән кадәр яшәмәс, әнә яшь кеше Айдарны куярга кирәк», – диючеләр булды. Һәм Айдарны куйдылар да. Тик бер елдан, 42 яшендә Айдарыбызның юл фаҗигасендә гомере өзелде. Ә кемнәрдер олы дигән агабыз, ковидны да җиңеп, башка чирләргә дә бирешмичә, әлхәмдүлилләһ, гамәл-гыйбадәттә яши.

...Тормышның уйландыра торган гыйбрәтләре дә, чагыштырып карардай мисаллары да күп. Күрер өчен күңел күзе генә кирәк. «Әй, нәрсәгә шаккатасың, нәрсәгә җәллисең», – дип кенә дә булмый... Бөтен нәрсәгә дә шулай тиеш, гадәти хәл дип, җиңел генә карасак, бәгырь дигәнебез ташка әйләнмәсме?

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

vk.com

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, «Лукойл» компаниясе Директорлар советы рәисе
Равил Өлфәт улы МӘГАНОВның
вакытсыз вафат булуы сәбәпле, туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Бу авыр минутларда сезнең белән без дә кайгырабыз.

ТАИФ компанияләр төркеме коллективы,
Ринат Нурислам улы ГӘРӘЕВ
вакытсыз вафат булу сәбәпле, туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Ринат Нурислам улы төрле елларда «РТТ», «Интеллектуаль челтәрләр», «ТаксНет» компанияләре белән җитәкчелек итте, «ТАИФ» ААҖ генераль директоры киңәшчесе булып хезмәт итте. Ул искиткеч кеше – менә дигән әти, ир һәм бабай иде. Ринат Нурислам улы безнең хәтеребездә Татарстан телекоммуникация өлкәсе үсешенә зур өлеш керткән менә дигән җитәкче булып кереп калыр. Аның якты истәлеге күңелләребездә озак сакланыр.

Белдерү

Кадастровым инженером Кутдусовой Натальей Генадьевной (СНИЛС № 128-830-216 57), являющейся членом СРО АКИ «Поволжье» (номер в реестре СРО 0182, дата вступления 05.07.2013 г.), квалификационный аттестат № 16-11-417, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1, адрес электронной почты: m2405085@yandex.ru, тел.: 8(843)2405085, в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:33:021150:149, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Пестречинский муниципальный район, Богородское сельское поселение, садоводческое некоммерческое товарищество «Алан», участок 98, выполняются кадастровые работы по уточнению границ и площади земельного участка.
Заказчиком кадастровых работ является Ибатуллина Г.Ф., тел.: +79276774801. Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования границ состоится по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1 3 октября 2022 г. в 10.30 минут. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1. Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются ежедневно с 9 до 17 часов с 12 сентября 2022 г. до 3 октября 2022 г. по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1.
Смежные земельные участки с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ:
1) земельный участок с кадастровым номером 16:33:021150:37, расположенный по адресу: Республика Татарстан, Пестречинский муниципальный район, Богородское сельское поселение, с/т «Алан», участок 99;
2) земельный участок, расположенный по адресу: Республика Татарстан, Пестречинский муниципальный район, Богородское сельское поселение, с/т «Алан», участок 97.
При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

Укырга, укырга һәм...



* * *

«Нәрсәгә инде ул миңа математика?» – дисең укыганда. Ә аннары кафеда дуслар белән төшке аш ашагач, чектагы саннарны бүлеп, очына чыга алмыйсың.

* * *

1 августтан бирле сөйләнелгән көн килеп җитте – 1 сентябрь. Котлыйбыз!

* * *

Валерьянка сатып алырга дип даруханәгә барган идем, алып бетергәннәр. Әллә укытучылар, әллә ата-аналар.

* * *

Югары белем тормышта бик кирәк. Әйтик, сез каравылчы булдыгыз, ди. Сканвордны ничек чишәчәксез?

* * *

Әгәр дә сез иң җиңел сканвордны да чишә алмыйсыз икән, димәк, сез – Достоевский романы, 5 хәреф.

Авырлыкларны без төрлечә узабыз.

ТӨШӘМЕ ИСЕҢӘ?

Авыл өе. Зур мич тора
Горур басып почмакта.
Әнкәем куллары аны
Буяп куйган ап-акка.

Ул чорның бойлеры иде
Зур казанда – кайнар су.
Тыштан туңып
керсәң әгәр,
Җылы мичкә аркаң куй.

Итек-бияләйләр кибә
Төннәрен мич башында.
Солдаттай
гел басып торды
Күмер чүлмәк, каршында.

Күмеркәйләр әзер торды
Куярга самавырны.

Дуслар килә, чакырмыйча,
Сизенеп сагынганны.

Хлорсыз кое сулары
Көттермәс, кайнап чыгар.
Чәй эчмичә чын татарым,
Белмим шул, ничек чыдар?!

Мич башында итекләргә
Помидор тутырдылар.
Алар шунда изрәп-пешеп,
Кызарып утырдылар.

Мичтә ипикәй пешкәндә
Өйләр тулды исенә.
Шигырь укучым, синең дә
Төшәме болар исеңә?

(Интернеттан)

Мач әйткән!

ЮРИЙ НИКУЛИН, цирк һәм кино артисты

Һәрберегез бер генә кешене бәхетле итегез, һәм бөтен дөнья бәхетле булачак!

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ ТИНЧУРИН ТЕАТРЫНДА

Менә сиңа бала!

Тинчурин театрында нәниләр өчен «Менә сиңа куш кулым» спектакле куелды. Тамашаның премьерасын карарга дип матбугат бүлегендә эшләүче танылган шәхесләр – Татарстанның атказанган артистлары Шамил Фәрхетдинов белән Илсур Мортаза да төшәләр. Мортаза арттарак кала. Шамилне күреп, директор урынбасары Марсель Шакиров төрттереп куя: «Пустышкаң кайда, бәбиләр спектакле карарга җыенасың бит!» Шамил югалып калмый: «Мин бит үзем өчен түгел, әнә баламны алып килдем!» – дип артта елмаеп басып торган Мортазага ишарәли.

«Кыр казларын...» җырла әле!

Бер елны Хәтер көнендә оештыручылар Исламия Мәхмүтованы Сөембикә-ханбикә итеп киендергәннәр. Менә аны «КамАЗ» машинасы кузовында урнаштырган тәхеттә Ленин урамы буйлап Кремльгә таба алып баралар. Шулчак ике хатын яраткан артисткаларына кычкырып калалар: «Исламия, «Кыр казларын...» җырла әле!»

Кайсы Әнәс?

Театрга яңа өстәлләр китергәннәр. Бушатырга кеше кирәк. Яңа гына эшли башлаган бер кызга: «Әнәскә әйт әле, ташып куйсын», – дигәннәр. Сүз сәхнә эшчесе Әнәс турында бара.

Теге кыз аны-моны уйламый, өлкән яшьтәге артист Әнәс Галиуллинга шалтыратып: «Әнәс абый, сезгә өстәл ташырга куштылар, срочно килегез!» – дигән. Күп тә үтми, тирләп-пешеп Әнәс абый да килеп җиткән. Эшнең нидә икәнлеген белгәч, рәхәтләнеп көлгәннәр, ди.

Җиләкле гастрольләр

1976 елда Равил Тумашев Туфан Миңнуллинның «Ак тәүбә, кара тәүбә» спектаклен чыгара. Төп роль Гомәрне Наил Шәйхетдинов башкара. Театр җәйге гастрольгә чыгып китә. Бер авылда Наил абыйның хатыны Миңнегөл ханым Зөләйха Хәкимҗанова белән күп итеп җир җиләге җыйган. Әрәм итеп булмый бит инде: кич, спектакль вакытында, сәхнә артында алар кечкенә электр плитәсендә шуннан кайнатма ясыйлар. Клуб эче башларны әйләндерерлек хуш ис белән тула. «Артистлар шулхәтле әйбәт уйнадылар, хәтта чын җиләк исләре чыккан кебек булды», – дип сөйләгән ди икенче көнне халык.

Актуаль шигырь

Тимер Зиннуров талантлы артист һәм оста гармунчы булудан тыш гаять җор телле дә була. Бервакыт артистлар гастрольгә кузгалалар. Юлда театр хәлләре, илдә бәяләр арту турында кызу гәпләшү булып ала. Шунда Тимер әфәнде җәһәт кенә шигырь чыгарып тора:

Бәяләр арта,
Күтәрелә тариф;
Квартплата түли алмый
Үлеп китте Гариф.

ИР – БАШ, ХАТЫН – МУЕН

* * *

Без хәзер шундый яшькә килеп җиттек, ирләргә дә, хатын-кызларга да бер үк әйбер кирәк: тагын бер көн ял.

* * *

– Матурым, һәрвакытта да интригага урын калдыр.
– Ничек итеп?
– Иртәгә әйтәм.

* * *

Ярый әле төнлә ЗАГСлар ябык, мин инде бишенче тапкыр кияүгә чыккан булыр идем.

* * *

Элеккеге сөйгәнеңә киләчәктә сиңа нинди кеше кирәк түгел икәнен аңлатканы өчен рәхмәтле бул.

* * *

Шул хөрмәткә бер тост:
– Гаиләгездә рюмка бары тик пилмән кисәр өчен генә тотылсын!

* * *

Әгәр син кызыңа айфон ала алмыйсың икән, алдан ук айфонлы кыз сайла.

Әз-мәз мәзәк

* * *

– Ник менәсең ул агачка?
– Алма ашыйм.
– Каен бит ул!
– Алманы үзем белән алдым.

* * *

Иң кыска резюме: «Бу хезмәт хакына миннән дә яхшыны таба алмассыз».

* * *

Офис хезмәткәре үзенең 5 яшьлек кызын эшкә алып килә.
– Әти, «минем эштә клоуннар эшли» дип әйтә идең. Клоуннар кайда?

* * *

Уйларың һәрвакыт позитив булсын. Мәсәлән: «Аның каравы әле тугыз бармагым бар бит».

* * *

– Исәнмесез. Минем исемем Руслан. Һәм мин зоопарктан крокодил урладым.
– Туктагыз әле, бу бит аноним алкоголиклар клубы.
– Ә сез ул вакытта мине аек иде дип уйлыйсызмы?

* * *

– Мәсәлән, юмор хисен алыйк.
– Каян алыйк?

Фотофакт

Бу коллаж түгел, бер фото. 2007 елның 8 июне. Австралия. Диңгездәге гарасат «Pasha Bulker» корабын Ноббис комлыгына чыгарып ата. Йортлар корабтан берничә метр арада гына кала.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

БОЛГАР КЫЗЫКЛАРЫ

«Амбар ишеге дип белдегезме әллә?»

Мәрхүм Зөфәр абый Мәхмүтов озак еллар райкомда шофер булып эшләде. Бигрәк тә тәртип һәм чисталыкны ярата торган кеше иде ул. Аның машинасына хәтта җитәкчеләр дә аяк киемнәрен сөртеп кереп утыра торган булган. Салонда тәмәке тартучыларны җене сөймәгән. КПССның Куйбышев район комитеты беренче секретаре Гурьевны йөрткәндә, райкомга өр-яңа «Волга» автомобиле биргәннәр. Николай Гурьевич үзе дә һәр җирдә тәртип булганны яратты, таләпчән, әйбернең кадерен белә торган кеше иде. Бервакыт беренче секретарьга тиз арада обкомга килеп җитәргә кушканнар. Ул тиз генә җыенып чыгып, райком каршында торган машинага кереп утыра да ишеген, үзе дә сизмәстән, шап итеп яба. Зөфәр абый шулчак түземе бетеп:

– Николай Гурьевич, амбар ишеге дип белдегезме әллә? Иплəп кенә ябып булмыймы соң аны? – дигән.

«Военком бирергә кушты»

90 нчы еллар башында авыл малайлары Болгар военкоматына медкомиссия узарга килгән. Бер көндә үтеп бетерә алмагач, кунакханәгә кереп кунганнар. Шаярышып булса кирәк, кырлы стаканны идәнгә төшереп ваткан болар. Иртә белән администратор бүлмәне тикшерергә керә. Караса, бер стакан юк. Кая куйдыгыз, дип таптыра башлаган администратор. Куркып калган авыл малайлары бер сүз дә дәшмәгәч, военкоматка шалтыраткан. Билгеле инде, комиссарның эшне катлауландырасы килмәгән: «Бер призывникны тиз генә минем янга җибәр», – дигән. Комиссар үзенең кырлы стаканын призывникка тоттырган да военкомат җитәкчесенә тапшырырга кушкан. Малай военкомат урынына партия райкомы бинасына килеп кергән һәм: «Моны призывниклар бирергә кушты», – дип ул вакыттагы җитәкче Еровның кабул итү бүлмәсендәгеләргә калдырып чыгып киткән. Кырлы стаканны беренче секретарьга тапшырганнар. Ул исә озак вакыт: «Нинди хикмәт булды соң бу?» – дип баш ватып йөргән.

«Безне япмасылармы?»

Болгардагы дәүләт музеена туристлар туктаусыз килеп тора. Аеруча җәйләрен.

Беркөн шулай Кара пулат каршында үскән юкәләрдән чәчәк өзеп торам. Экскурсовод белән туристлар килә. Иң арттан бәләкәй кызын җитәкләгән ханым атлый. «Кара пулат элек төрмә ролен дә үтәгән» дигән сүзләрне ишеткәч, кызчык әйтеп куя: «Әни, безне ябып куймаслармы соң? Тәрәзәләре томаланган өй янында торуыбызны шалтыратып әтигә әйтикме әллә?» «Экскурсовод апаң сөйләгәннәрне генә тыңлыйбыз да аннан Ак мәчеткә китәбез», – дип тынычландырды әни кеше. «Ярар алайса, – дип куанды кыз бала. – Син барыбер шалтырат, алай-болай була калса, әти безне төрмә тирәсеннән эзләп йөрмәсен».

Бу әңгәмәне ишеткән туристлар рәхәтләнеп көлештеләр.

Тәлгать ҖАМАЛЕТДИНОВ

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6708 данә
Гомуми тираж – 15890 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 328

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+